| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ**
17.03.2026

**БОЕРЫК**
№ 332-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентын расларга

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 26.05.2022 № 308-пр боерыгын;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында» 21.11.2024 № 675-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыкларына кертелгән үзгәрешләрнең 1 пунктын.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
17.03.2026 № 332-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ Регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

Шартлы билгеләр һәм кыскартмалар исемлеге бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

1.2. Гариза бирүчеләр булып тора: Татарстан Республикасының дәүләт автоном, бюджет, казна учреждениеләре һәм Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләре (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар нигезендә тиешле вәкаләтләр бирелгәнлеген раслаган вәкилләр (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) эш йөртә ала.

Гариза бирүчеләрнең категория идентификаторы (билгеләре) бу Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүченең категорияләренә (билгеләренә) туры китереп күрсәтелә, аның турында белешмәләр “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы), “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru/) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның мөлкәт идарәсенең дәүләт мөлкәтен арендалау һәм реализацияләү бүлеге (алга таба - Бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне сатулашулар үткәрү юлы белән арендага бирүне килештерү турында карар;

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне сатулашулар үткәрмичә арендага бирүне килештерү турында карар;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында хат).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында мәгълүмат системасында реестр язуы формалаштыру каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерүне гариза бирүче үзе сайлаган ысул буенча ала:

гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки электрон документ формасында;

электрон документ формасында гариза бирүченең Республика порталындагы, “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмати система” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы http://lk.eisestate.tatar.ru (алга таба - ЕИС «Имущество») шәхси кабинетына;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба - МФЦ) Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземплярны формасында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Дәүләт мөлкәтен арендага бирүне килештерү турында гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан шәхсән яисә почта аша бирелгән очракта,

мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты гариза кергән көннән алып 22 эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинет аша бирелгән булса, гаризага эш номенклатурасына туры китереп номер һәм Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетта күренеп торучы «Документларны тикшерү» статусы куелган көннән соң 22 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүчеләрнең бөтен категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан МФЦ аша бирелгән булса, дәүләт хезмәте, МФЦ Регламентында каралган срокны да истә тотып, 22 календарь көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Министрлыкта һәм МФЦда дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гариза бирүче күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Республика порталын, ЕИС «Имущество»ны, Министрлыкның рәсми сайтын кулланган башка түләүләр каралмаган. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты - 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросын регистрацияләү срогы

2.7.1. Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос МФЦдан кергән көнне Министрлык тарафыннан регистрацияләнә.

Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦның Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән регистрация номерлы расписка бирелә.

2.7.2. Гариза Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү ала.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

2.7.3. Гариза почта аша юлланса, гариза бирүчегә гариза Министрлыкка кергән көнне электрон почта белән гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән белдерү юллана.

2.7.4. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, гариза бирелгән көнне министрлык хезмәткәре гариза алынуын раслаган, гариза бирү датасы һәм регистрация номеры күрсәтелгән расписка бирә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтына, Республика порталына, ЕИС «Имущество»га урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә мөрәҗәгать итсә, гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) консультация бирелә ала.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, гариза бирү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә, теләсә кайсы МФЦда, үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда, мөрәҗәгать итүченең кайда булуына карамастан (юридик затлар өчен) сайлавы буенча экстерриториаль принцип буенча гамәлгә ашырыла.

2.10.4. МФЦда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.5. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәләре буенча күпфункцияле үзәккә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне таныклауны да кертеп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү каралган.

2.10.6. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында, ЕИС «Имущество»да урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Республика порталы, ЕИС «Имущество» аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Республика порталында, ЕИС «Имущество»да электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.10.7. Гариза формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Республика порталындагы, ЕИС «Имущество»дагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган гаризаларга да.

2.10.8. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, ЕИС «Имущество», Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегәраслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә каршылык тудырмый.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы, ЕИС «Имущество» кулланыла.

2.10.11. Әлеге Регламентта Татарстан Республикасы милке булган мөлкәт булып түбәндәгеләр күзаллана:

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

«Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14 ноябрь 2002 ел № 161-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 161-ФЗ Федераль закон) 18 статьясында билгеләнгән очракларда күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

милек иясенә беркетелгән яисә әлеге мөлкәтне алу өчен милек иясе бүлеп биргән акчаларга автоном учреждение сатып алган аеруча кыйммәтле күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

милек иясенә беркетелгән яисә әлеге мөлкәтне алу өчен милек иясе бүлеп биргән акчаларга бюджет учреждениесе сатып алган аеруча кыйммәтле күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

күчемле милек.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге

2.11.1. Закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән: алар мөрәҗәгать итүче үзе мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка, һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документларга бүленә.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формасы шушы Регламентның 5 нче, 6 нчы кушымталарында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен

күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категориясенә керми торган затның гариза белән мөрәҗәгать итүе;

2) документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән

3) әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар формасы әлеге Регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.12.4. Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) гариза бирүче тапшырган документларда дөрес булмаган белешмәләр булуы;

2) хокук билгели торган документлардан мөрәҗәгать итүче мөлкәте белән оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукын бәхәссез раслау факты күренми;

3) Гариза бирүченең алдагы аренда мөнәсәбәтләрендә үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәве:

- элегрәк төзелгән аренда килешүләре буенча дәүләт мөлкәтен арендалаган өчен Татарстан Республикасы бюджеты каршында бурычлары булу (казна учреждениеләре өчен);

- килештерү йомгаклары буенча төзелә торган дәүләт мөлкәтен арендалау килешүләрен, элегрәк төзелгән килешүләргә өстәмә килешүләрне (үзгәрешләр кертү турында, вакытыннан алда өзү турында), аренда килешүенең гамәлдә булу срогы беткәч, арендаторның аренда бирүчегә арендаланучы мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын тапшырмау (үз вакытында тапшырмау);

- элегрәк төзелгән аренда килешүләрен Министрлык белән килештермичә озайту;

- аренда бирүченең аренда килешүләре буенча башка йөкләмәләрен бозуы.

4) сатулашу уздыруның монополиягә каршы законнар белән билгеләнгән зарурлыгы (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза тапшырганда);

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүчене гамәлгә куючы яки Министрлык тарафыннан, билгеләнгән тәртиптә, мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан карар кабул ителү;

6) законлы көченә кергән әлеге мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан суд карары;

7) Татарстан Республикасы мөлкәтен арендалау кыймматен бәяләү турындагы тапшырылган отчетның бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законына туры килмәве;

8) ТР буенча Росреестр мәгълүматлары нигезендә, мөрәҗәгать итүченең арендага бирүгә тәкъдим ителә торган күчемсез мөлкәткә хокуклары булмау;

9) Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм реестрында мөрәҗәгать итүчене (дәүләт мөлкәтен сатулашу булдырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендаторны) юкка чыгару турында яки аның эшчәнлеген туктатып тору турында карар булу, яисә мөрәҗәгать итүче (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендатор) турында мәгълүматлар булмау;

10) мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрында күздә тотылган арендатор турында мәгълүматлар булмау (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына медицина оешмаларына арендага биргәндә).

2.12.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән формада.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә (дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), административ процедура таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү үткәрелә торган административ процедураны гамәлгә ашыру, дәүләт хезмәте күрсәтү

турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны), мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатланырга рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын күздә тоткан бүленеш каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене профильләү;

2) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати арадашлык;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан эшләү (проактив) режимында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Техник мөмкинлеге булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның запросы статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат аша;

– Республика порталы аша;

– ЕИС «Имущество» аша;

– башка сервислар һәм ысуллар кулланып (булса).

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
1нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
3. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне исәпкә алу һәм идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы – ЕИС «Имущество» (http://lk.eisestate.tatar.ru);
4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы – Министрлык;
5. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – МФЦ.
6. Дәүләт милке яисә муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә ликвидацияләү турында, оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, шулай ук, балалар өчен социаль инфраструктура объектларына карата түләүсез файдалану шартнамәсе төзү нәтиҗәләрен бәяләү буенча оешманы үзгәртеп оештыру яисә ликвидацияләү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия – Нәтиҗәләрне бәүләү буенча комиссия

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе атамасы | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне сатулашулар үткәрү юлы белән арендага бирүне килештерү турында карар | Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе | 1А |
| 2. | | Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе | 2А |
| 3. | | Татарстан Республикасы казна учреждениесе | 3А |
| 4. | | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 4А |
| 5. | | Татарстан Республикасының балалар өчен социаль инфраструктура объекты булган дәүләт автоном, бюджет, казна учреждениесе | 5А |
| 6. | | гариза бирүченең вәкиле | 6А |
| 1. | Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне сатулашулар үткәрмичә арендага бирүне килештерү турында карар | Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе | 1Б |
| 2. | | Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе | 2Б |
| 3. | | Татарстан Республикасы казна учреждениесе | 3Б |
| 4. | | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | 4Б |
| 5. | | Татарстан Республикасының балалар өчен социаль инфраструктура объекты булган дәүләт автоном, | 5Б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | бюджет, казна учреждениесе | |
| 6. | | гариза бирүченең вәкиле | 6Б |

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Кәгазь документ формасындагы гариза | почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Электрон формадагы гариза | Республика порталы, ЕИС «Имущество» (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) |
| 2. | 1А-6А,<br>1Б-6Б | Шәхесне раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 6А,6Б | гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ | МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 6А<br>6Б | гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе | почта аша юллаганда, МФЦга яки |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә, Республика порталы, ЕИС «Имущество» |
| 5. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналарның планировкасы күчермәләре һәм биналарның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган техник паспорты нигезендә аларга эшләнгән экспликация | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 6. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Арендага бирү өчен билгеләнгән җиһазларның юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган исемлеге (арендага бирелерлек җиһаз булган очракта) | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 7. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Дәүләт мөлкәтенең билгеле бер вакыт чорына аренда (аренда түләве ставкалары) бәясе турында бәйсез бәя куючының отчеты | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 8. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Мөлкәтне арендага бирүнең максатка ярашлылыгын нигезләү | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 9 | 1А-6А<br>1Б-6Б | Арендага бирү өчен тәкъдим ителә торган биналар һәм бүлмәләрнең | Республика порталы, ЕИС |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | электрон форматтагы фотосурәтләре | «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 10. | 1А, 1Б<br>5А, 5Б<br>6А, 6Б | автоном учреждениенең багучылар шурасының мөлкәт белән эш итү буенча алыш-биреш ясау турындагы тәкъдимнәре | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 11. | 2А, 2Б<br>3А, 3Б<br>6А, 6Б | Казна учреждениеләре (күчемле мөлкәтне арендага биргәндә) һәм бюджет учреждениеләре өчен (бюджет учреждениеләре тарафыннан “Коммерциячел булмаган оешмалар турында” Федераль законның $9^2$ статьясындагы 13 пунктында билгеләп куелган нигез билгеләренә туры килүче эре алыш-биреш, яки “Коммерциячел булмаган оешмалар турында” Федераль законның 27 статьясында билгеләп куелган нигез билгеләренә туры килгән мәнфәгатьләр булган алыш-биреш башкарылганда) өстәмә | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 12. | 5А, 5Б<br>6А, 6Б | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә ликвидацияләү турында карар кабул итү нәтиҗәләренә бәя бирү чарасы | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үткәрү хакында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, шулай ук, Татарстан Республикасының социаль милек объектларын тәшкил иткән дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яисә ликвидацияләү турында» 09.08.2022 № 775 карарына туры китереп әзерләнгән нәтиҗәләрне бәяләү буенча комиссия бәяләмәсе | |
| 13. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Татарстан республикасы милке булган мәдәни мирас объектын кулланучының вәкаләтле орган тарафыннан рәсмиләштерелгән саклау йөкләмәсе күчермәсе (мәдәни мирас объектларын түләүсез файдалануга тапшыру очрагында) | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 14. | 1Б-6Б | күздә тотылган арендатор – юридик затның уставы яки нигезләмә күчермәсе | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 15. | 1Б-6Б | күздә тотылган арендатор – юридик затның җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куелу турындагы карар күчермәсе | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 16. | 1Б-6Б | күздә тотылган арендатор – шәхси эшмәкәрнең дәүләт мөлкәтен | Республика порталы, ЕИС |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | арендага бирү турында гариза күчермәсе | «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булып, дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшыра алган документлар | | | |
| 1. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Арендага тапшырылырга тиешле күчемсез милек турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Россия Федерация субъектының башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле органыннан мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4. | 1А-6А<br>1Б-6Б | Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрыннан өземтә - Татарстан Республикасы | Республика порталы, ЕИС «Имущество», почта аша |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фондыннан | юллаганда, МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткәндә |

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
4 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен ачыклау, группа документлары саны |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә карамаган затның мөрәҗәгате |
| 2. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | документларны башка вәкаләтле органга тапшыру - гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү кермәгән органга бирелгән |
| 3. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны тапшырмау |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | гариза бирүченең моннан алдагы аренда мөнәсәбәтләрендә үз бурычларын тиешенчә үтәмәве:<br>- элегрәк төзелгән аренда килешүләре буенча дәүләт мөлкәтен арендалаган өчен Татарстан Республикасы бюджеты каршында бурычлары булу (казна учреждениеләре өчен);<br>- килештерү йомгаклары буенча төзелә торган дәүләт мөлкәтен арендалау килешүләрен, элегрәк төзелгән килешүләргә өстәмә килешүләрне (үзгәрешләр кертү турында, вакытыннан алда өзү турында), аренда килешүенең гамәлдә булу срогы беткәч, арендаторның аренда бирүчегә арендаланучы мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын тапшырмау (үз вакытында |

| | | |
|---|---|---|
| | | тапшырмау);<br>- элегрәк төзелгән аренда килешүләрен Министрлык белән килештермичә озайту;<br>- аренда бирүченең аренда килешүләре буенча башка йөкләмәләрен бозуы. |
| 2. | 1Б – 6Б | сатулашу уздыруның монополиягә каршы законнар белән билгеләнгән зарурлыгы (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага бирүне килештерү турында гариза тапшырганда) |
| 3. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүчене гамәлгә куючы яки Министрлык тарафыннан, билгеләнгән тәртиптә, мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан карар кабул ителү |
| 4. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | Татарстан Республикасы мөлкәтен арендалау кыйммәтен бәяләү турындагы тапшырылган отчетның бәяләү эшчәнлеге турындагы Россия Федерациясе законына туры килмәве |
| 5. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | законлы көченә кергән әлеге мөлкәт белән эш итүнең башка төрле тәртибен күз алдында тоткан суд карары |
| 6. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | ТР буенча Росреестр мәгълүматлары нигезендә, мөрәҗәгать итүченең арендага бирүгә тәкъдим ителә торган күчемсез мөлкәткә хокуклары булмау |
| 7. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм реестрында мөрәҗәгать итүчене (дәүләт мөлкәтен сатулашу булдырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендаторны) юкка чыгару турында яки аның эшчәнлеген туктатып тору турында карар булу, яисә мөрәҗәгать итүче (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына арендага биргәндә расланучы арендатор) турында мәгълүматлар булмау; |
| 8. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрында күздә тотылган арендатор турында мәгълүматлар булмау (дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча гына медицина оешмаларына арендага биргәндә) |
| 9. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | гариза бирүче тапшырган документларда дөреслеккә |

| | | |
|---|---|---|
| | | туры килмәгән мәгълүматлар булу |
| 10. | 1А – 6А<br>1Б – 6Б | хокук билгеләүче документларда гариза бирүче оператив идарәнең яисә мөлкәт белән хуҗалык итүченең бәхәссез хокукы факты күренми |

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына
________________

Дәүләт мөлкәтен сатулашулар үткәрү юлы белән
арендага тапшыруны килештерүгә
ГАРИЗА

Гариза бирүче: ____________________________________________________________________
(Оешма атамасы)

________________________________________________________________________йөзендә
(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме (булса))

Мөлкәтне (объект) _____ вакытка арендага тапшыруны килештерүегезне сорыйм

атамасы __________________________________________________________________________

(беркетелгән исемлек нигезендәге бина, җиһаз)

Бина төре _________________________________________________________________

(административ, производство, склад, башка төр)

арендага бирелә торган объектның максатчан билгеләнеше ————————————————————

| **Мөлкәтнең (бүлмәнең) адресы:**<br>42________ , ______________ел<br>Район ______________________<br>______________________урамы<br>______________________йорт | **Бүлмәнең тасвирламасы:**<br>Мәйданы: ________________ $м^2$<br>Подвалда __________________ ,<br>цокольда _____________________,<br>____________________ катта,<br>___________ катлы бина.<br>Аерым керү урыны (әйе/юк) | **Бинада** (әйе/юк):<br>Электр уты___________<br>Үзәкләштерелгән җылыту ________________<br>Су _________<br>Канализация ___________ |
|---|---|---|
| **ТИБ техник паспорты**<br>**әйе / юк** | Җир төзү документлары: җиргә дәүләт акты<br>әйе / юк, дата ____________________________________<br>**Кадастр өземтәсе: әйе / юк ; дата__________________** | |

| **Төзелгән датасы:** | **башкалар** ___________________________________________<br><br>**Дата** ______________________ |
|---|---|

Тапшырылган мәгълүматларны раслыйм: ____________________________________________________________

| Гариза бирүченең имзасы: _________________________ м.п. Дата: ____________ _____ |
|---|

| Оешманың тулы атамасы ______________________________________________________<br><br>__________________________________________________ ОКПО _______________________________<br><br>_____________________________________________ нигезендә гамәл кылучы<br><br>җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме________________________________<br><br>________________________________________ ,<br><br>Оешманың юридик адресы: 42_____________ , ел. __________________________________ |
|---|

| Балансга торучы бүлмәләрнең гомуми мәйданы кв. м _______________________________<br><br>Төзелгән килешүләр буенча арендага бирелгән мәйдан, кв. м _____________________________<br><br>Оешманың арендатор белән эшләү буенча вәкаләтле заты ________________________________________телефон_________________________________________ |
|---|

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ____________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземплəры рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында, ЕИС «Имущество»га шәхси кабинетка);

- Министрлыкка бирергә _____________________

_______________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземпляры рәвешендә кәгазьдә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: _______________________.

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
6 нчы кушымта

Рекомендуемая форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына
_________________

Дәүләт мөлкәтен сатулашу уздырмыйча
арендага бирүне килештерүгә
ГАРИЗА

Гариза бирүче: ____________________________________________________________________

( Оешма атамасы)

____________________________________________________________________ йөзендә

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**Мөлкәтне (объектны) _____________ срокка арендага бирүне килештерүегезне үтенәм**

атамасы ________________________________________________________________________

(кушымта итеп бирелүче исемлеккә туры килә торган бүлмә, җиһаз)

бинаның тибы ____________________________________________________________

(административ, җитештерү, склад, башкалар)

бирелә торган объектның максатчан билгеләнеше__________________________________

_____________________________________________________________________________

тәкъдим ителә торган арендатор (атамасы, ИНН) ___________________________________

| **Мөлкәтнең (бүлмәнең) адресы:**<br>________ , г. _______________<br>Район ________________________ | **Бүлмәнең тасвирламасы:**<br>Мәйданы: ________________ $м^2$ | **Бинада**<br>(әйе/юк): |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| ур. ___________________________ йорт ___________________________ | Подвалда ___________________ , цокольда ______________________, ____________________ катта, ___________ катлы бина. Аерым керү урыны (әйе/юк)_____ | Электр уты___________ Үзәкләштерелгән җылыту ________________ Су _________ Канализация ___________ |

| | |
|---|---|
| **ТИБ техник паспорты** **әйе / юк** **Датасына төзелгән:** | Җир төзү документлары: җиргә дәүләт акты әйе / юк, дата ____________________________________ **Кадастр өземтәсе: әйе / юк ; дата__________________** **Башкалар_____________________________________________** **Дата ______________________** |

**Тапшырылган мәгълүматны раслыйм:**

Гариза бирүченең имзасы: ____________________________ м.п. Дата: ___________________

Оешманың тулы атамасы _______________________________________________________

_________________________________________________ ОКПО _________________________________

_______________________________________________ нигезендә гамәл кылучы

җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме__________________________________

__________________________________________ ,

Оешманың юридик адресы: 42_____________ , ел. ____________________________________

Район ______________________, ______________________________урамы, (

Баланста торучы бүлмәләрнең гомуми мәйданы кв. м _________________________________

Төзелгән килешүләр буенча арендага бирелгән мәйдан, кв. м ______________________________

Оешманың арендатор белән эшләү буенча вәкаләтле заты __________________________________________телефон___________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә ______________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземплярлы рәвешендә кәгазьдә; Республика порталында, ЕИС «Имущество»га шәхси кабинетка);

- Министрлыкка бирергә ______________________

_________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярлы рәвешендә кәгазьдә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: ________________________.

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
7 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

(Орган бланкы)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

Дата _________________________ № _______________

По результатам рассмотрения заявления на согласование сдачи в аренду государственного имущества от _______________№_________________ и приложенных к нему документов, на основании утвержденного административного регламента Министерством _____________________принято решение ________________.

Дәүләт мөлкәтен арендага бирүне килештерүгә _______________№_________________гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, Министрлыкның расланган _______________________ административ регламенты нигезендә карар кабул ителде ________________.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен ачыклау:
_____________________________________________________________________________;
_____________________________________________________________________________;___
____________________________________________________________________________.

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: ______________________________________.

Сез күрсәтелгән кимчелекләрне төзәткәннән соң дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән дәүләт хезмәте күрсәтергә вәкаләтле органга _____________________________ яңадан мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтергә вәкаләтле органга судка кадәр, шулай ук, сул тәртибендә шикаять ителә ала.

Вазыйфа ______________________ (Фамилия, инициаллар)
(Имза)

Татарстан Республикасы милкендә
булган мөлкәтне арендага бирүне
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
8 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

(Орган бланкы)

Дәүләт хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү

_______________________________________________

(юридик зат – гариза бирүче атамасы)

гариза № _______ _____._____.________, _________________мөрәҗәгатенә бәйле
_______________________________________________
нигезендә:
_______________________________________________

_______________________________________________

бирелгән документларны карау нәтиҗәсендә түбәндәге сәбәпләр аркасында документларны кабул итүдән баш тарту (документларны кире кайтару) турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфа _____________________ (Фамилия, инициаллар)

(Имза)

Башкаручы (ФИӘИ)

_________________________

(башкаручының контактлары)